**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.03.2021 № 227

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

- «Россия Федераль салым хезмәте законнарын бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч булу (булмау) турында белешмәләр.»;

2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«законнар бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч булу (булмау) турында белешмәләр.»;

3.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«законнар бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч булу (булмау) турында белешмәләр.»;

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 февралендәге 61 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары М.Х. Хабибулловага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин